ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы,
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40, факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 21 » 09 2018г. № 29

Референдум уздыруны тәкъдим итү турында

2003 елның 6 октябреннән булган “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 маддәләре, 2002 елның 12 июненнән булган “Россия Федерациясе гражданнарының төп сайлау хокуклары гарантияләре һәм референдумда катнашуга хокуклары турында”гы №67-ФЗ Федераль законның 15 маддәсе, 2004 елның 28 июленнән булган “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45-ЗРТ Законның 15 маддәсе, 1 пункты, Татарстан Республикасының 2004 елның 25 мартыннан булган “Җирле референдум турында”гы №23-ЗРТ Законының 12 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставының 12 маддәсенә ярашлы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе башкарма комитеты
к а р а р и т ә:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум уздыруны тәкъдим итәргә:

“Сез 2019 елда Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе территориясендә Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән гражданинга 300 (өч йөз) сум күләмендәге суммада (Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, 1нче, 2нче төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан тыш) һәм бер тапкыр түләнелә торган салым күләмен киметеп, көндезге формада укучы студентлар өчен 150 (йөз илле) сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге сорауларны хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына караган юл эшчәнлегенә:
- Пушкин урамына асфальт җәюгә;
- Горький урамында тротуар төзү буенча эшләр башкаруга;
2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыруга:
- Сугышчы -интернационалистлар-әфганчылар истәлегенә” скверын төзекләндерүгә.

“ӘЙЕ” “ЮК”

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы Советына юнәлтергә.

3. Әлеге Карарны Интернет челтәрендә Ютазы муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру һәм җирлекнең махсус мәгълүмати стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге Карар халыкка җиткерелгән көннән соң көченә керә.

5. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы З.Н. Айтыкина